АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.04.2019 №244

Алексеевск ш.т.б.

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексына, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатында,

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 2018 елның 14 сентябрендәге 193 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яллаучының (эш бирүченең) вәкиле район башлыгы, җирле үзидарә органы җитәкчесе, район сайлау комиссиясе рәисе яки яллаучы (эш бирүче) вәкаләтләрен үтәргә бурычлы булган башка зат булырга мөмкин.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Алексеевск муниципаль районында Россия Федерациясе дәүләт телен белүче гражданнарның муниципаль хезмәткә тигез үтемлелеге, җенескә, расасына, милләтенә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, иҗтимагый берләшмәләргә, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең профессиональ һәм эшлекле сыйфатларына бәйле булмаган башка шартларга бәйсез рәвештә аны үтү шартлары да бертигез булуы гарантияләнә.»;

11 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 11.4, 11.5 пунктларын өстәргә:

«11.4 Житәкче булган муниципаль хезмәткәр,җирле үзидарә органында мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарә органының сайлау профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен әлеге вазыйфаны биләү чорында яклый алмый.

11.5 Граждан,муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы, тиешле муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туган булган очракта(ата-аналары, ирле-хатынлы, балалары, бертуганнары, шулай ук ирләренең яки хатыннарының бертуганнары, ата-аналары, балалары һәм балаларының ирләре, хатыннары), муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфасына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфасын били алмый.»;

12.1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләре (устав капиталында катнашу өлешләре), оештыру яки идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә; федераль законнарда каралган башка очракларда шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш; җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, шул исәптән сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу; съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу; күрсәтелгән коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән һәм профоюз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан тыш) бер генә башкарма орган сыйфатында яки аларның коллегиаль идарә органнары составына муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә алынган эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән түләүсез нигездә катнашу), муниципаль берәмлекнең идарә итү органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлекнең гамәлгә куючысы (акционеры) булган муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итүдән тыш катнашырга;»;

12.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.4. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән граждан,Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән билгеләнгәнчә, әгәр әлеге оешма белән муниципаль (административ) идарә итүнең аерым функцияләре муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссия ризалыгы белән муниципаль хезмәт эшеннән киткәннән соң ике ел дәвамында оешмада хезмәт килешүе шартларында вазыйфаларны биләү һәм (яки) гражданлык-хокукый килешү шартларында (гражданлык-хокукый килешүләр)бу

оешмада бер ай дәвамында түләү бәясе йөз мең сумнан артмаган эшне башкару (әлеге оешмаларга хезмәт күрсәтү)хокукына ия.»;
27.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«27.3. Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 17, 18 һәм 32 статьяларында каралган түләтүләр Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында һәм (яисә) муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиле (эш бирүче) тарафыннан түбәндәге нигезләрдә кулланыла:

1) коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;

2) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия тәкъдимнәре, тикшерү нәтиҗәләре турында доклад комиссиягә җибәрелгән очракта;

3) коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсенең коррупцион хокук бозулар турында доклады, анда аны башкаруның факттагы шартлары һәм муниципаль хезмәткәрне бары тик аның ризалыгы белән һәм коррупцион хокук бозу фактын таныган очракта гына язмача аңлатуы бәян ителә (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге җәза кулланудан тыш);

4) муниципаль хезмәткәр аңлатмалары;

5) башка материаллар.».

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 2018 елның 13 декабрендәге «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү туында»217 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 2019 елның 4 февралендәге «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 226 номерлы карары.

3. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Совет рәисе урынбасары Г. В. Беловага йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**